СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**09.09.2016**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№88**

Зеленодольск шәһәре Советы карарына «2012 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2011 елның 17 октябрендәге 63 номерлы (Зеленодольск шәһәре Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 197 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге 292 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге 17 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 башлыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «2012 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2011 елның 17 октябрендәге 63 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (Зеленодольск шәһәр Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 197 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге 292 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге 17 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 1.8 пунктчасы белән тулыландырырга:

«1.8. Шифаханә-курорт оешмалары белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата 0,1%»;

2) 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

"- Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советы карары нигезендә сәнәгать мәйданчыклары проектлары гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлекләренә карата идарәче компанияләр һәм оешмалар».

3) 4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасы 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел;

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасы рәсми басылып чыкканнан соң бер ай узгач үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә үз көчен тарата.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасы әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз гамәлләрен тарата.

5. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Яшел Үзән шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**